УДК 82.512.145(092)Туфан
ББК 83.3 Тат
Х 91

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла

**Редколлегия:**

филология фәннәре докторы, профессор ***К. М. Миңнуллин (рәис),***
филология фәннәре докторы, профессор ***Н. Ш. Хисамов,***
филология фәннәре кандидаты ***Д. М. Абдуллина***

**Төзүчеләр:**

филология фәннәре кандидаты ***Р. Ф. Рахмани (фәнни мөхәррир),***
филология фәннәре кандидаты ***Ф. Х. Миңнуллина***

**Х 91 Хәсән Туфан: давылларда, җилләрдә:** Хәсән Туфанның тууына 110 ел тулуга багышланган төбәкара фәнни-гамәли конференция материаллары (8 декабрь, 2010 ел). – Казан, 2010. – 247 б.
ISBN 978-5-93091-130-5

Җыентыкта күренекле классик шагыйребез Хәсән Туфанның тууына 110 ел тулу уңае белән уздырылган фәнни-гамәли конференция материаллары, каләмдәшләренең әдип турындагы хатирәләре, аның катлаулы озын гомер һәм иҗат юлын яктырткан иң кызыклы язмалары туплап бирелә.

**ISBN 978-5-93091-130-5**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2010

*— Бөгелсәнә, каен, иелсәнә,*
*Аякларым җиргә тимәсме?*
*— Бөгелер идем, буем каты минем,*
*Үтәр хәл юк синең киңәшне.*

*— Сәлам тапшыр, каен, — диде егет,*
*Тынып калды шунда аннары...*
*Бер эндәште каен, өч эндәште,*
*Бүтән бер сүз ишетә алмады.*

*Яфраклары коела ак каенның,*
*Яфраклары коела яшь кебек.*
*Үле булса тирбәләдер төсле*
*Шул каенга аскан яшь егет.*

*Әйтегез лә шушы ак каенга:*
*— Елама син, каен, аппагым,*
*Киң кырларда үзе генә түгел,*
*Эзе дә юк инде ятларның.*

Әгәр 30–40 нчы елларда шагыйрь еш кына табигатьнең үзен аңларга омтылса, 50–60 нчы елларда табигать, чынбарлык күренешләре аша кеше рухындагы катлаулы кичереш-хисләрне *«материальләштереп сурәтләргә тырыша»*. Туфан лирикасында *«Урал, Себер, тайга образлары янына дала, чүл сурәтләре, дөнья, галәм, ерак мәңгелек шикелле үзенчәлекле һәм күләмле символлар килеп өстәлә»*.

Табигать — әдипнең гомере буе юлдашы да, дусты да, киңәшчесе дә булды. Х. Туфан иҗатын табигатьтән башка күз алдына китерү мөмкин түгел.

**Х.Туфан иҗатын мәктәптә өйрәнү мәсьәләләре**

Укучыларга белем һәм тәрбия биргәндә, үзебезнең туган җиребездә яшәгән, хезмәт иткән күренекле шәхесләребезнең тормышын, иҗатын файдалану отышлырак. Табигатькә карата мәхәббәт тәрбияләгәндә, шагыйрь иҗатына тукталып була. Туфан табигатьтәге нәфислектә, гармониядә, ишлелектә бездә туачак матурлыкка, кешеләр арасындагы камил мөнәсәбәтләргә тиң үрнәк өлге таба. Шагыйрь табигать тормышында тирән эчке мәгънә күрә, тереклек күрке — су тамчысында, яфрак җилфердәвендә, ак каен зарында, йолдызлар җемелдәвендә сурәтләнә.

Хезмәт тәрбиясе биргәндә, әтисенең кечкенәдән үк балаларны эшкә өйрәтеп үстерүен һәм бу һөнәрнең Туфанны ач үлемнән коткарып калуда мөһим роль уйнавын аңлатып була.

Җыр-моңның зур көчкә ия булуы турында сөйләшкәндә, Хәсәннең бала вакытында ике урам малайлары арасындагы бәрелеш вакыйгаларын тасвирларга мөмкин.

Туган илгә мәхәббәт тәрбияләгәндә, Туфан иҗатындагы үзәктә торган тугрылыкны раслау тора. Кеше үз юлында, язмышында нинди генә авырлык һәм низагларга очрамасын, ул Ватанына тугрылыклы калырга тиеш.

Уңай һәм тискәре геройлар турында сөйләшкәндә, Туфан камерада утырган вакытта яшь табибның ярдәмен, сакчының тәмәке бирү вакыйгаларын китерергә мөмкин.

Бер-береңә ярдәмләшү, кешелеклелек хисләре тәрбияләгәндә, Х. Туфан үз бригадасына үлем бусагасына баскан кешеләрне алып, аларга исән калырга булышуы, үз паегы белән бүлешү очракларын алырга була.

Чын дуслык, тугрылык темасына әңгәмәдә төрмәдә вакытта Туфанга ялган документларга кул куйдырырга тырышу алымнарын күрсәтү хас. Туфан әхлакый сафлык, рухи гармония өчен көрәшне — тормыш өчен көрәшнең аерылгысыз өлеше дип карый.

Икмәк кадере турында сөйләшкәндә, Туфанның камерада утырган вакытларында шигырьләрен ничек икмәк эчендә яшереп саклавы, икмәккә иң изге әйбер итеп карауны мисалга китерергә була.

Шигърияттең бөеклеге турында сүз барганда, кеше үтерүчеләр камерасында утыручыларны да Туфан үз шигырьләре һәм әкиятләре аша буйсындыруын күрергә мөмкин.

Мәхәббәт, гаилә, әхлак проблемалары хакында тәрбия биргәндә, Луиза Салигаскарованың ире Хәсән гомерен саклап калу өчен үз канын сатып төрмәгә ризыклар илтү мисалын китерергә була.

Туганнар арасында ярдәмчелек, теләктәшлек хисләрен чагылдырганда, Туфанга абыйларының ярдәмен үрнәк итеп алырга була.

Гомумән, Х. Туфанның язмышы, шигърият теле, язып калдырган фикерләре авырлыкларны җиңеп, киләчәккә ышанып яшәргә өмет уята. Ул абыйсына язган бер хатында болай ди:

*«Күңел күзе белән карый алганда, дөнья матур. Тормыш та ямьсез түгел. Нинди генә авыр шартларда торсаң да, әгәр киләчәктә иманың һәм йөрәгең тыныч булса, яшәүнең һәр сәгатендә җанга берәр төрле мәгънәви азык табып була».*

# МӘКТӘПТӘ ТАБИГАТЬ ФӘННӘРЕН ӨЙРӘНҮДӘ ХӘСӘН ТУФАН ШИГЫРЬЛӘРЕ

*Ф. М. Сабирова (Алабуга)*

Белгәнебезчә, мәктәптә әдәбият дәресләрендә Хәсән Туфанның данлы да, трагик хәл-вакыйгалар белән дә тулы тормыш юлы, моның алшартлары һәм нәтиҗәләре белән җентекле итеп, бер төрле перспектива белән өйрәнелә. Укучылар аның шигырьләрен анализлап, аларның сәнгатьчә үзенчәлеген, идея-эстетик кыйммәтен танып беләләр. Укытучыга адресланган методик чыганаклар да булу бу төр дәресләрнең нәтиҗәлелеген күтәрүдә ярдәм итә (1, 2). Шуларга өстәп, укучыларга Туфанның иҗат эшенә бик тә җаваплы каравына, күп очракта

киеренке «техник» эшләр дә башкаруы турында үрнәкләр китерү максатка ярашлы. *«Язган әсәрләремне тикшерергә ятам, — дип яза Хәсән Туфан. — Шигырьне язып бетергәч тә ниндидер "доктринам" бар, шуның "аксиома" икәнлеген ачасы бар кебек тоела.*

*"Күк чәчәкләр — авыру сөяркә, —*
*Алар кырда солы иптәшләргә*
*Төзәлмәслек йогыш иярткән..." —*

*дигән фразаның дөреслеген сынау өчен, бер ай буена Союз күләмендә үткәрелгән авыл хуҗалыгы күргәзмәсенең отчетларын, иске "Правда"лардан Сосновскийның авыл хуҗалыгы турындагы фельетоннарын укып, бакраның (василек) һәр ел саен Союзга миллион зарар китерүен өйрәндем.*

*"...Тиңсез чәчәк бездә ничек үсәр? —*
*бездә җир шаклы, сулар — мазутлы" —*

*дигән фразаны реаль чәчәк рәвешендә алып тикшердем... Мазут һәм җир күмере төтеннәре тирәсендәге газлар турында өйрәндем. Укыдым. Таныш химикларым белән киңәштем»* (3, 88).

Иҗатын производство темасы белән башлаган Хәсән Туфан гомере буе шул темага турылыклы булып кала. Хәтта тоткынлык елларында язылган әсәрләре дә шагыйрьнең фән һәм техника яңалыкларыннан яхшы ук хәбәрдарлыгы, ул яңалыкларының асылы һәм нәтиҗәләре белән танышлыгы турында сөйли. Димәк, ышанып әйтергә мөмкин: төгәл һәм табигать фәннәрен өйрәнгәндә дә «техник» материалга «лирик» төсләр биреп җибәрү өчен шигырьләр байтакка җыела.

Әле башлангыч сыйныфларда ук табигать белеме дәресләрендә тәүлек һәм анда көн белән төн чиратлашу (җирнең үз күчәре тирәсендә әйләнүе белән бәйле), ел фасыллары һәм аларның бер-бер артлы килү (җирнең кояш тирәсендә әйләнүе белән бәйле) сәбәпләрен танып белгәннәрне системага салу максаты белән укытучы укучыларга Хәсән Туфанның «Көнле-төнле ике йөзле тәүлек...» (1960) дип башланган (исемсез) шигырен тарата:

*Көнле, төнле — ике йөзле тәүлек*
*Безнең гомер көнен кыскарта.*
*Яз, җәй узса, көзгә тотынып ук,*
*Сызгырынып уйнап, кыш кайта.*

*Юк, ышанмый әле җаным һаман*
*Булыр дип бер чик гомергә.*
*Барын бар ул, ләкин юктыр сыман,*
*Булмас кебек тоела күңелгә.* (4, 175)

Шигырь укыла һәм аңа әңгәмә ялгана: ни өчен шагыйрь тәүлекне «ике йөзле» дип атый? Тәүлекне «ике йөзле» дип бәяләве белән хаклымы? Нәрсәгә таяна ул? «Икейөзле» дип күнелендәгесен әйтмичә, ялагайланып йөргән кешеләргә карата да әйтәләр. Шагыйрь тәүлекне дә икейөзлелектә гаепләмидер бит?! (Юк, әлбәттә, шагыйрь тәүлекнең төп ике кисәге барлыгына ишарә итә: берсе — көн, икенчесе — төн. Ике йөзле тәүлек «ничә йөзле тәүлек?» соравына җавап булып килә, аерым языла. Ике йөзле булу — тәүлекнең табигый сыйфаты. Икейөзле кеше... Ике тамыр кушылып язылган, «нинди?» соравына җавап килә, җанлы табигать — кеше — күздә тотыла. Хәсән Туфанны бу очракта җансыз табигать күренешләре тирән уйландыра. Шагыйрь ел фасылларыннан кышка хас бер генә билгене телгә ала: *сызгырынып*. Әлеге бер сүз белән кышка хас нинди сыйфатларны белдерүгә ирешә ул? Яз, җәй, көзләрне сыйфатламый шагыйрь. Бу эшне безгә калдыра кебек. Йә, без үзебезгә тапшырылган эшне башкарыйк әле: яз, җәй, көзгә хас билгеләрне тулы итеп тасвирлыйк... Һәр ел фасылының әнә шулай үзенә генә хас сыйфатлары булуны нәрсә белән аңлатырга? Хәсән Туфан үз шигырендә ел фасылларының тәртибен яз, җәй, көз, кыш итеп бирә. Нигә икән? Югыйсә бит яңа ел кыш көннәреннән, гыйнвардан башлана... Шундыйрак (яки башкачарак) сорау һәм биремнәрне үтәү төгәлләнгәч, укытучы шигырьнең объектив эчтәлеген ассызыклап куя: көн, төн, ел фасыллары — табигатьнең бик тә йөгерек күренешләре. Алар бер-берсен куа, бер-берсен алыштыра бирәләр, кешеләрнең дә гомере уза тора. Исән-сау чакта үзеңнән соң да матур истәлекләр калсын, сагынып искә алсыннар өчен, күңелең гүзәл булу, файдалы эшләр башкарып калу кирәк.

VII сыйныфта физика яңа предмет буларак өйрәнелә генә башлый. Шуңа күрә дә өр-яңа төшенчәләр дөньясына кергәләгәнче, укучыларга якын, таныш нәрсәләргә, әдәби әсәрләр, бигрәк тә шигырь укырга яратуларына таянырга туры килә. Укучыларны *физиканың* табигать турындагы фән икәнлеге белән таныштыруны укытучы, Хәсән Туфанның «Гүзәл гамь» шигыреннән, тактага язылган өзекне уку белән башлый:

*«Ни» түгел, син*
*«Кем»дер, табигать.*
*Бардыр синең берәр ниятең?*
*Белмәмешкә салышып кына*
*Син нәрсәдер иҗат итәсең*
*Никадәрле төсләр чәчкәндә,*
*Никадәрле төсләр, шәкелләр* (формалар) —
*Бу иҗатың каршында синең*
*Без адәмнәр — бары шәкертләр.* (4, 8)

Шигырь сәнгатьле итеп укыла, аннары әңгәмәдә уза: шигыре аша Хәсән Туфан үзенең нинди хисләре белән уртаклаша? (Соклану, ис китү). Шагыйрьнең табигатькә әнә шулай ис китеп соклануын нәрсәләрдән белеп була? (Җанлы кешегә эндәшкән кебек «кем» дип эндәшә, гаҗәпләнеп, сорау бирә, табигатьтәге төс, төр, формаларны санап китә, аларның күплегенә исе китеп гаҗәпләнә, соклана). Чынында җанлымы табигать? (Юк. Җансыз табигать турында сүз бара. Туфан үзе дә «кем»дер дип, аптыраганнан гына «кем» дип әйтергә мәҗбүр булуын кисәтеп куя).

— «Бу иҗатың каршында синең / Без адәмнәр — бары шәкертләр» юлларын сез ничек аңлыйсыз? — соравын куеп, укучыларның фикерләрен тыңлагач, укытучы табигать дөньясын гаять күп төсләр, төрләр, формалар, күренешләрне махсус фән өйрәнүен, аның *физика* дип аталуын әйтә. Шуннан соң, төрле методик алымнар кулланып, физиканың барлык профессия кешеләре өчен дә әһәмиятен, гадәти тормышта кулланыла торган физик

приборларны (тузан суырткыч, телевизор, сәгать, телефон физик күренешләрне төшендерә, «фәнни терминнар» төшенчәсен аңлата, физик белемнәрнең чыганаклары, «матдә», «җисем», «материя» кебек төшенчәләрнең уртак һәм аермалы яклары белән таныштыра. Укучылар мөстәкыйль рәвештә әйтелгән күренешләрне үзләренә хас сыйфатлары белән язып куялар: туп тәгәри, кургашын эри, боз суыта, күк күкрәү авазлары яңгырый h. б.

Дәресне йомгаклап, укытучы табигатьтәге күп төрле формаларны белү кешенең белемен арттыруы, табигать алдында көчле итүе, теләсә нинди профессия сайлауга хәзерләве турында сөйли: төрле формалар эченә төрле иксез-чиксез *эчтәлек* тупланган ич. Һәм тагы Хәсән Туфан:

*Ачарсың атом серен,*
*Белерсең барсын да син.*
*Нинди яшь әле, Кеше,*
*Мәңгелек каршында син!* (4, 88)

«Диффузия» темасына барган дәресне дә күзәтеп карыйк. Укучылар диффузияне *күренеш* буларак танып беләләр, аның сәбәпләрен һәм механизмын төшенәләр, тәҗрибәләр ясап һәм күзәтеп, диффузиянең төрле җисемдә төрлечә була алуы һәм температурадан бәйле икәнлеге турында нәтиҗә ясыйлар. Менә укучыларга Хәсән Туфанның «Яр буенда икәү йөриләр...» (4, 89) дип башланган исемсез шигыре таратыла. Укыгач ачыклана: баштагы ике строфада шагыйрь диңгез ярына ялга дип килгән егет һәм кыз белән таныштыра. Бу ят җирләр караңгы кебек тоела, үзләренең туган якларын, андагы яктылыкны сагыналар.

*Егет күңеле:*
*— Менә шунда китереп куйсаң*
*Әлмәт факелының берәрсен!... —*

дигән кебек.

Төп һәм дәрес өчен кирәкле фикер түбәндәге строфага тупланган:

*Ә Гөлсинә юри кырт кисмәкче:*
*— Рәхмәт, — диеп, — сезгә халыктан —*
*Каз итендә керосин тәме,*
*Мазут исе килә балыктан...*

Строфа диффузия күренешен төрле компонентларда күз алдына китерергә мөмкинлек бирә:

— факел (ялкын) һәм һава молекулалары үзара аралашу, тирә-юньгә яктылык таралу;

— нефть, аның исе, молекулаларының җир молекулалары арасына үтеп керүе, җирнең исләнүе;

— нефть, мазут, нефть-мазутлы җир исе молекулаларының су молекулалары белән аралашуы, суның агулануы;

— h. б.: агулы су — балык (тәнендә бушлык-аралыклар бар), агулы су — каз (тәнендә бушлык-аралыклар бар)...

— Тозлаган кыярны (помидорны) күпмедер вакыт чиста суда тотканнан соң, ни өчен кыярда (помидорда) тоз тәме кими?... Мазутлы, нефтьле казны (балыкны) чиста суда күпмедер тотып торгач, каз, балык тәмендә нинди үзгәрешләр көтәргә мөмкин?... — кебегрәк сораулар биргәннәр соң, укытучы сыйныф игътибарын Туфан шигыренең язылу вакытына игътибар итә. 1962 ел. Бу XX йөзнең җитмешенче еллары башы — җәмгатьчелекнең фән-техника яңалыкларының, бигрәк тә нефть чыгару һәм эшкәртүнең табигатькә зур зарар китерүе мәсьәләләрен күтәреп чыккан вакыты. Җитмешенче еллар уртасына инде экологик проблема буларак куела һәм кабул ителә. Табигатьне ярату, аның гүзәллегенә соклану, үләннәрне таптамау, кошларга җим бирү, аларга тимәү генә, бик тә мөһим булса да, аз хәзер. Белемле хуҗа булып, грамоталы саклауга, сафлыгы өчен актив көрәшчеләргә мохтаҗ бүген изге Табигать-ана.

Укучыларга бер физикадан гына түгел, әйтик, географиядән, астрономиядән белгәннәрне искә төшерергә (интеграция) ярдәм итә торган биремнәр өчен дә шигырьләр Туфанда җитәрлек. Әйтик, кинематика нигезләреннән «координата», «координаталар системасы», «күчеш», «координаталар үзгәреше», «җисем хәрәкәтенең башлангыч моменты», «җисемнең соңгы торышы», «җисем хәрәкәтенең юнәлешле күчеше» кебек төшенчәләр танып беленгән, үзләренә хас формулалары үзләштерелгән, мисаллар китерелгән. Һәр укучыга Хәсән Туфан шигыре язылган карточка таратыла.

*Юл авыр булган саен.*

*Татарча әйтсәң генәдер*
*Чамалап була аны:*
*— Сездә дә бардыр гомернең*
*Җиде төн урталары.*

*Болытсыз төннәр түрендә*
*Сез — Тимерказык сыман!*
*Мин сезгә багып-чамалап*
*Азимут язып куям.*

*Уятып, уйландырып, сез*
*Кәрванны, туганнарым,*
*Яктырак яна барасыз,*
*Юл авыр булган саен!..* (4, 287)

Шигырь сәнгатьле итеп укыла, аның лирик мәгънәсе турында фикерләшү уза (тормыш юлын узу өчен — гомер узган саен, ул авыраяа бара — таяныр өчен терәк — йолдызлар кирәк. Йолдызлар — күчерелмә мәгънәдә: ышанычлы, яхшы күңелле, эчкерсез кешеләр; дуслар...).

Сораулар һәм биремнәр гадәти тормышта халык телендә «җиде төн уртасы» дип нәрсәгә әйтелүенә, Тимерказыкның болытсыз төнгә нинди катнашы барлыгына, җиде төн уртасы Тимерказыкны кайсы яклап билгеләвенә, кәрваннар төнлә йөрүчән булуына, Тимерказыкның күк йөзендә хәрәкәт үзенчәлегенә аңлатма бирелә h. б.

Механикада саклану законнарын үткәндә Хәсән Туфанның

*— Артмыйм да мин, кимемим дә... — дисең, Матдә. —*
*Яшим, үсәм һәм үзгәрәм... — дисең, Матдә.*
*Бу Галәмдә бер атом да арталмагач,*
*Бу эшеңнең төп мәгънәсе ни соң, Матдә?!* (4, 141) —

робагыенда куелган поэтик сорау, күрәбез, танып белү соравы да булып тора. Матдәнең саклану законы (бер җирдә кимесә, икенче җирдә, урында арта) — табигатьнең

универсаль законы, һәм саклану үзлеге механикада гына түгел, хәтта физиканың барлык бүлекләрендә генә дә түгел, башка фәннәрдә дә әһәмиятле роль уйныйлар. Саклану законының химик реакцияләргә бәйләнешле рәвештә М. В. Ломоносов тарафыннан ачылуы да шул хакта сөйли.

Китерелгән робагыйга килгәндә, аның эчтәлеге, төзелеш үзенчәлеге һәм сәнгатьчә чаралары аша җисемнең импульсы да, энергиясе дә, импульслар системасы турында да бик иркен фикер йөртеп була. Укучылар кызыксынып китсә, Туфанның «Атомнарым минем мәңге үлмәс...» дип башланган исемсез шигырен дә өстәп укырга була (4, 90), я өйдә укырга тәкъдим итәсең. Шигырьнең, матдәнең саклану законына кагылышы булса да, үз нюансы да күзәтелә: шагыйрь бертөрле юмор белән атомнарга аң, уйлау сыйфаты бирә. Бәхесләшкән дә кебек — мөмкинме бу? Шагыйрьнең мәңгелек, җан, яшәүнең мәгънәсе турында фәлсәфи уйлануларын кебек тә кабул ителә.

Туфан поэзиясе күпкырлы. Аның шигырьләрен укыган саен, дөнья хәлләреннән булсын, кеше яшәешеннән булсын, хәбәрдарлыгың артканнан арта бара. Кайчагында аның турында «әллә махсус астрономияне өйрәнгән инде!», — дип куясың. Шунда Габдрахман Әпсәләмов сүзләре искә төшә: «Туфан — тирән уйлар, саф һәм зур хисләр шагыйре, — ди ул. — Аның иҗатында еш очрый торган космик атамалар — галәм киңлекләре, галактика атом, материяләр — болар матур сүзләр яки модага бирелү түгел, бәлки Туфан шигъриятенең тирәнлегеннән күтәреләләр, анда укмашалар, анда яралалар» (5, 156).

Астрономиядән беренче дәрескә үк укучыларга яраткан шагыйрьләренең образлар системасында күк йөзе, күк җисемнәре (ай, кояш, йолдызлар, җирнең ясалма иярченнәре һ. б.) булган шигырьләрен сайлап укырга тәкъдим ителә. Хәсән Туфан поэзиясеннән «Сәлам», «Безнең нәни», «"Ай 9"га», «Кайтты бүген», «Гүзәл гамь», «Җиделәр», «Юл авыр булган саен», «Кем көчлерәк?», «Дөрли-дөрли кычкыра галәм...», «Сез кая барасыз, йолдызлар?», «Дөм караңгы галәм чүлендәге...», «Тел дигәннең берсен генә түгел...», «Миссиясен үзенең тәгәл үтәп...» шигырьләре булырга мөмкин. Алар, кирәге чыккан саен, дәресләрдә искә төшерелә торалар. Ә беренче дәрестә күк җисемнәренең поэзиядә бирелү үзенчәлеге турында кыскача сөйләшү булып ала: шагыйрьләр күк йөзе, күк җисемнәренә, яратып, еш мөрәҗәгать итәләр, аларның матурлыгына, гармониале булуына сокланалар, җанлы итеп, җир, кешеләр белән төрле мөнәсәбәтләргә кертеп тасвирлыйлар, тирән хисләр, киеренке фикерләргә өретеп бирәләр. Аннары укытучы укучылардан кемнең күк йөзен күзәткәнен, анда ниләр күрә алуын, шунда нинди хисләр кичерүен, нәрсәләр турында уйлавын сораштыра. Хәсән Туфанның «Дөм караңгы галәм чүлендәге...» шигыреннән бер строфа китерик:

*Лирикларга йолдыз, Галактика —*
*Иң романтик хисләр сәхрәсе.*
*Фәнгә-галимнәргә бу Галәмнең*
*Җитми икән тагын нәрсәсе?*

Шигырьдән «Галактика», «Галәм» сүзләре аерып алына һәм «галактика» сүзенә конкрет мисал итеп Хәсән Туфан шигырьләрендә еш очрый торган Җидегән йолдыз образы алына. «Галәм» төшенчәсен конкретлаштыру өчен, Хәсән Туфанның «Сөйли торган материя» шигыре укыла.

— «Фәнгә-галимнәргә бу Галәмнең // Җитми икән тагы нәрсәсе?» — дип гаҗәпләнә бит шагыйрь Хәсән Туфан, — дип мөрәҗәгать итә сыйныфка укытучы. — Кемнәр кызыксына Галактика белән?.. Йолдызлар һәм йолдызчыклар системасы, планеталарны кайсы фән өйрәнә?

Йолдызлыклар, йолдызлы күк белән танышу дәресендә Хәсән Туфанның «Сез кая барасыз, йолдызлар!» шигыре искә төшерелә дә сорау куела: өзектә нинди астрономик күренешләр бар?

*Планеталар нидер ымлашалар.*
*Кукләргәрәк, өскәрәк менеп,*
*Кайларгадыр барган йолдызларның*
*Җитәр җирен күзләгән кебек.*

*Әйтерсең, бу чиксез мәңгелектә*
*Берәр чиккә җитәргә мөмкин? —*
*Әйтерсең лә, орбитаңнан чыгып,*
*Кая булса китәргә мөмкин?..* (6, 254)

Айның гомуми табигате танып беленгәч, Хәсән Туфанның «"Ай 9"га» шигыре материалның үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү өчен уңай:

*Җайлап кына, йомшак кына*
*Утырсаң да тын Айга,*
*Син Давыллар океанын*
*Сайлагансың шулай да.* (6, 248)

Тын Айда нинди Давыл булырга мөмкин? Сусыз урында океан, диңгезләр буламы, атмосферасыз давыл кубамы? кебек сораулар куелгач, укучылар Айда гади күз белән дә озынга сузылган каракучкыл таплар булуы һәм аларның башта диңгез дип уйлануы, әмма тора-бара анда су булмавы ачыклануы турында сөйлиләр. Шулай да галимнәр (Дж. Риччоли) «диңгез» терминын саклап калдыра һәм үзәнлекләргә сәер исемнәр бирә: «Давыл океаны», «Кризислар диңгезе», «Тынычлык диңгезе», «Яңгырлар диңгезе». Телескоп аша күзәтүләр әле 1610 елда ук Ай өстендә ачыграк төстәге калкулык-таулар да барлыгы ачыла (Г. Галилей), аларга да җирдәге тау исемнәре бирелә (Я. Гевелий): Апенниннар, Кавказ, Альп һ. б. Шуларга бәйләп, Айның өйрәнелүе, 1986–1910 елда аның зур атласы төзелүе һәм басылып чыгуы, 1958 елда бездән «Ай-1» дигән космик аппарат җибәрелеп, аларның саны тора-бара 21 гә җитүе, Хәсән Туфан шигырен «Ай-9» аппаратына багышлап язуы, Луноходлар җибәрелүе, АКШның бу өлкәдә актив эшчәнлеге турында мәгълүматлар китерелә.

Астрономияне өйрәнүгә гомуми йомгак ясау эшенә дә Хәсән Туфан ярдәмгә килә кебек. Мисалга аның «Дөм караңгы галәм чүлендәге...» шигыренә язган эпиграфын алыйк:

*Соңгы сүзен әйтер өчен микән,*
*Чал астроном килеп керде бүген иртән:*
*— Галәм ничек яралганны белдем, — диде, —*
*Әмма нигә яралганын белми китәм.*

— **Ничек** яралган соң? Моның нәтиҗәләре нәрсәләрдә күренә? Нәрсәләрдән гыйбарәт?.. **Нигә** яралган соң ул Галәм? Астрономга ярдәмгә ничегрәк итеп җавап бирик икән?.. — Укучылар алдына куелган сораулар болар.

Мәкаләне тәмамлап, шуны гына ассызыклап куйыйк: физиклар белән лириклар арасында бәхәс хәзер «Кем яхшырак? Кем кирәгрәк» юнәлешендә түгел, «Кем хәзерлеклерәк? Кем чыны белән заман кешесе, ягъни физик та, лирик та?» тәртибендә бара. Мәктәпкә чыны белән заман кешесен тәрбияләү бурычы йөкләнгән бүгенге көннәрдә, дәресләрдә интеграция күренешләрен арттыру конкуренциягә хәзерлекле шәхесләр тәрбияләү чараларының берсе булып санала ала. Чөнки

*Физикада нинди атом булса,*
*Шигырьдә дә шундый атомнар.*
(Х.Туфан)


ӘДӘБИЯТ

1. Мифтахова М.А. Хәсән Туфан мәктәптә / М.А.Мифтахова. – Алабуга: АДПИ ризотипографиясе, 2002. – 110 б.
2. Мифтахова М.А. Поэзия Хасана Туфана 60–80 гг. XX в.: Проблема лирического героя. Методика изучения в татарской школе / М.А.Мифтахова. – Казань: Алма-Лит, 2005. – 204 с.
3. Туфан Х. Үзем турында / Х.Туфан // Әдәби мирас: Өченче кисәк / Төз. Г.Гыйльман. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1996. – Б. 86–89.
4. Туфан Хәсән. Гүзәл гамь: Моңарчы басылмаган шигырьләре / Хәсән Туфан. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1990. – 303 б.
5. Әпсәләмов Г. Киек каз юлы кебек... / Г.Әпсәләмов // Ак чәчәк атар иде: Хәсән Туфан турында истәлекләр / Төз. Х.Әюпов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 156.
6. Туфан Хәсән. Сайланма әсәрләр: Ике томда / Хәсән Туфан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – II т. – 366 б.
7. Туфан Хәсән. Лирика / Хәсән Туфан; төз. Нил Юзиев. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1980. – 319 б.


# ТРОПА, ПРОЛОЖЕННАЯ К ТУФАНУ
## (Проблема изучения произведений Хасана Туфана в школе)


***А.Ю.Михайлов** (Емелькино, Аксубаевский район)*


В последние годы наконец-то приходит понимание того, сколь много потеряно там, где нет воспитания детей на своих национальных традициях, на примере национальных героев, известных людей родного края. Стали забываться народные промыслы, уходят из жизни русские, татарские, чувашские умельцы, несущие своё искусство из глубины веков, из старины глубокой, а дети плохо знают традиции и обычаи своего и соседних народов, и даже традиции своей семьи.

Я работаю учителем русского языка и литературы в Емелькинской средней школе Аксубаевского района 15 лет. Кроме уроков языка и литературы веду краеведческий кружок по авторской программе «Мы — татарстанцы».

Творчеством нашего земляка — татарского поэта Хасана Туфана заинтересовался в 2000 году. Так получилось, что мы, краеведы нашей школы, волею судьбы оказались на открытии дома-музея поэта 13 декабря 2000 года в селе Старая Киреметь Аксубаевского района РТ. Сюда в этот день приезжал и первый президент Татарстана М.Ш.Шаймиев.

«Его судьба — подвиг, его личность не может не вызывать уважения. В годы репрессий этот человек провёл в заключении 16 лет, но это не сломило его духа, он не озлобился на людей, — сказал тогда Минтимер Шарипович. — Это достойный сын своего народа, он дорог всем нам».

В этот же день состоялось открытие бюста Хасану Туфану. Его автором является не менее известный скульптор Махмут Гасимов.

С тех пор прошло 10 лет. Благодаря авторской программе по дополнительному образованию детей я выпустил методическое пособие «Знаешь ли ты Аксубай?» в помощь руководителям школьных музеев, классным руководителям, учителям истории и литературы для проведения занятий по родному краю, в котором помещена разработка краеведческого занятия «Жемчужина татарской поэзии», посвящённая любимому поэту. Данное занятие мы проводим каждый год в виде заочной и очной (расстояние до Старой Киремети от нас 30 км. — *А.М.*) экскурсии по дому-музею Туфана. Наша цель: прививать чувство гражданственности и патриотизма воспитанникам кружка на примере жизни и творчества видного татарского поэта, формировать интерес к изучению своего края.

С тех пор, как открылся на родине поэта музейный комплекс, народ потянулся в этот край нескончаемым потоком. Сюда приезжают люди, уважающие Хасана Туфана, туристы, полюбившие край поэта, краеведы, вновь и вновь открывающие для себя разного по характеру Поэта, Человека и Гражданина.

В последние годы проблемой изучения произведений поэта на уроках русской литературы в нашей школе заинтересовались и мои учащиеся старших классов. Вместе мы подготовили урок-исследование на тему «Прости мне, Родина, что я не соловей...» с использованием национально-регионального компонента.

На уроке работало 5 секций. ***Литературоведы*** (1 секция) подготовили сообщения о жизни и творчестве поэта через интернет-ресурсы. ***Чтецы*** (2 секция) учили наизусть стихи, готовили краткий анализ лирических произведений. Задачей ***журналистов*** (3 секция) было оформление компьютерной презентации, посвящённой жизни и деятельности Х.Туфана. ***Художники*** (4 секция) рисовали иллюстрации к произведениям. И, наконец,